**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзаларын раслау турында**

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **карар бирәм:**

1. Түбәндәге затларны Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары итеп расларга:

Большаков Андрей Георгиевич – Казан (Идел буе) федераль университеты Социаль-фәлсәфә фәннәре һәм массакүләм коммуникацияләр институтының конфликтология кафедрасы мөдире;

Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызы – «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы директоры;

Габдрахманов Фәнил Исхак улы – хезмәтне саклау төбәкара ассоциациясе рәисе;

Гафиятуллин Мөнир Минхәйдәр улы – «СКАТ» акционер җәмгыяте генераль директоры;

Иннокентий (Васецкий Иван Степанович) – Рус Православие Чиркәвенең (Мәскәү Патриархаты) Казан епархиясе викарие, Алабуга епископы;

Кадыйров Тимур Рәфкать улы – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе каршындагы Татарстан халыклары яшьләр ассамблеясе» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы советы рәисе, «Татарстанның Халыклар дуслыгы йорты» дәүләт бюджет учреждениесенең балалар һәм яшьләр белән эшләү бүлеге мөдире;

Кыямов Руфат Рифгать улы – «Татарстан Республикасы Студентлар лигасы» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы президенты;

Леушин Борис Дмитриевич – «Татарстан Республикасының комсомол ветераннары берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе;

Манина Юлия Сергеевна – «Татарстан Республикасы гражданнар башлангычларына ярдәм күрсәтү үзәге» төбәк иҗтимагый оешмасы президенты, «Электораль технологияләр платформасы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы башкарма директоры;

Морозов Кузьма Николаевич – «ИМАН» продюсерлык үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры;

Мостаев Рим Шагали улы – генерал-майор, Әфганстан Республикасында хәрби хәрәкәтләрдә, Төньяк Кавказ төбәге территориясендә коралды конфликтларда һәм террорчылыкка каршы операцияләрендә катнашучыларга бәйле мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы координация советы президиумы әгъзасы;

Поляков Александр Дмитриевич – «Россия ветераннар берлеге» бөтенроссия ветераннар иҗтимагый оешмасының «Татарстан Республикасы ветераннар берлеге» республика ветераннар (инвалидлар) иҗтимагый оешмасы рәисе урынбасары;

Реснянская Наталья Леонидовна – «Егоза» мәгариф үзәге» автоном коммерциячел булмаган гомуми белем бирү оешмасы директоры;

Садыйкова Дилбәр Әсадулла кызы – «Татарстан Республикасының Туристлыкны үстерү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры;

Сафин Тимур Фәдбир улы – Татарстан Республикасының «Безнең эш» гражданнар башлангычларына ярдәм күрсәтү төбәк иҗтимагый хәрәкәте рәисе;

Тимирясова Асия Витальевна – В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты (Икътисад, идарә һәм хокук институты) ректоры;

Тунакова Юлия Алексеевна – А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ Автоматика һәм электрон приборлар төзү институтының гомуми химия һәм экология кафедрасы мөдире;

Хәсәнов Илфар хәзрәт (Хәсәнов Илфар Ренат улы) – Татарстан Республикасы мөфтиенең рәсми органнар белән хезмәттәшлек буенча урынбасары, «Кол Шәриф» мәчете имамы;

Шакирҗанов Рафаэль Мәҗит улы – «МЭЛТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең тышкы икътисадый эшчәнлек буенча киңәшчесе;

Шиллер Дмитрий Августович – «Татарстан Республикасының су асты спорты федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы президенты, «Рус география җәмгыяте» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасындагы төбәк бүлекчәсе рәисе.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 18 декабрь
№ ПУ-762